ГЛАВА
БУТЛЕРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БУТЛЕРОВКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2021 с. Мокрые Курнали №9

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын**
**кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Бутлеровка авыл җирлегенең Юеш Көрнәле**
**авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлегенең Юеш Көрнәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 17 декабреннән 18 декабренә кадәр график нигезендә билгеләргә (Кушымта).
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Бутлеровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту;
- урамнарны яктырту;
- спорт мәйданчыгын төзекләндерү;
- һәлак булганнарга һәйкәлне төзекләндерү;
- парк зонасын төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Бутлеровка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы** **И.Л. Хушанова**

Кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлегенең Юеш Көрнәле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын этаплап уздыру**
**ГРАФИГЫ**

| Тәртип саны | Үткәрү датасы | Үткәрү вакыты | Үткәрү урыны | Урамнарның исеме |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 17.12.2021 | 09.00 | Юеш Көрнәле АМЙ, Юеш Көрнәле ав., Мәктәп ур., 9 й. | Урман ур., Тыныч ур. |
| 2 | 17.12.2021 | 11.00 | Юеш Көрнәле АМЙ, Юеш Көрнәле ав., Мәктәп ур., 9 й. | Яшьләр ур., Тау буе ур. |
| 3 | 17.12.2021 | 13.00 | Юеш Көрнәле АМЙ, Юеш Көрнәле ав., Мәктәп ур., 9 й. | 1 нче Яңа төзелеш ур. |
| 4 | 17.12.2021 | 15.00 | Юеш Көрнәле АМЙ, Юеш Көрнәле ав., Мәктәп ур., 9 й. | 2 нче Яңа төзелеш ур., Пионер ур., 2-13 й. |
| 5 | 18.12.2021 | 09.00 | Юеш Көрнәле АМЙ, Юеш Көрнәле ав., Мәктәп ур., 9 й. | Пионер ур. 14-26 й., Елга ур., Бакча ур. |
| 6 | 18.12.2021 | 11.00 | Юеш Көрнәле АМЙ, Юеш Көрнәле ав., Мәктәп ур., 9 й. | Совет ур. |
| 7 | 18.12.2021 | 13.00 | Юеш Көрнәле АМЙ, Юеш Көрнәле ав., Мәктәп ур., 9 й. | Мәктәп ур. |